ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-1,1-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«06» февраль 2025 ел** **№ 184**

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының “2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү” программасын раслау турында” 2019 елның 26 ноябрендәге 1039 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (28.04.2020ел №322, 28.09.2020 ел №735, 06.04.2021 ел №239, 22.12.2021 ел №2263, 01.04.2022 ел № 243, 02.03.2023 ел № 243, 13.04.2023 ел № 442, 05.05.2023 ел № 490, 15.02.2024 ел “118, 2024 елның 8 маендагы 315 номерлы үзгәрешләр белән)**

Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының “2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү программасын раслау турында” 2019 елның 26 ноябрендәге 1039 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (28.04.2020ел №322, 28.09.2020 ел №735, 06.04.2021 ел №239, 22.12.2021 ел №2263, 01.04.2022 ел № 243, 02.03.2023 ел № 243, 13.04.2023 ел № 442, 05.05.2023 ел № 490 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының “2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү программасын раслау турында” 2019 елның 26 ноябрендәге 1039 номерлы карарына (28.04.2020ел №322, 28.09.2020 ел №735, 06.04.2021 ел №239, 22.12.2021 ел №2263, 01.04.2022 ел № 243, 02.03.2023 ел № 243, 13.04.2023 ел №442, 05.05.2023 ел № 490, 15.02.2024 ел “118, 2024 елның 8 маендагы 315 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның исемендә “2020-2024” саннарын “2021-2025” дип үзгәртергә.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«____ »__________ 2025 ел** **№**

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының “2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү” программасын раслау турында” 2019 елның 26 ноябрендәге 1039 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (28.04.2020ел №322, 28.09.2020 ел №735, 06.04.2021 ел №239, 22.12.2021 ел №2263, 01.04.2022 ел № 243, 02.03.2023 ел № 243, 13.04.2023 ел № 442, 05.05.2023 ел № 490, 15.02.2024 ел “118, 2024 елның 8 маендагы 315 номерлы үзгәрешләр белән)**

Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының “2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү программасын раслау турында” 2019 елның 26 ноябрендәге 1039 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (28.04.2020ел №322, 28.09.2020 ел №735, 06.04.2021 ел №239, 22.12.2021 ел №2263, 01.04.2022 ел № 243, 02.03.2023 ел № 243, 13.04.2023 ел № 442, 05.05.2023 ел № 490 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының “2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү программасын раслау турында” 2019 елның 26 ноябрендәге 1039 номерлы карарына (28.04.2020ел №322, 28.09.2020 ел №735, 06.04.2021 ел №239, 22.12.2021 ел №2263, 01.04.2022 ел № 243, 02.03.2023 ел № 243, 13.04.2023 ел №442, 05.05.2023 ел № 490, 15.02.2024 ел “118, 2024 елның 8 маендагы 315 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның исемендә “2020-2024” саннарын “2021-2025” дип үзгәртергә.

1.2. Арча муниципаль районы башкарма комитетының “2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү программасын раслау турында” 2019 елның 26 ноябрендәге 1039 номерлы карарына (28.04.2020ел №322, 28.09.2020 ел №735, 06.04.2021 ел №239, 22.12.2021 ел №2263, 01.04.2022 ел № 243, 02.03.2023 ел № 243, 13.04.2023 ел №442, 05.05.2023 ел № 490, 15.02.2024 ел “118, 2024 елның 8 маендагы 315 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган “2020 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү” программасын кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телкоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарыЭ.Ш.Вафинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитеты
карарына Кушымта
06.03. 2025 ел № 184

**“2020 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү”**
**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Муниципаль программа исеме | “2020 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында<br>физик культураны һәм спортны үстерү” муниципаль программасы (алга таба – программа) |
| Муниципаль программаны эшләү өчен нигезләр | “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон; “2016-2020 елларга Россия Федерациясе гражданнарын патриотик тәрбияләү” дәүләт программасы турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 30 декабрендәге 1493 номерлы карары; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 7 августындагы 1101-р номерлы карары белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә физик культураны һәм спортны үстерү стратегиясе; 2008 елның 8 октябрендәге “Физик культура һәм спорт турында” 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2013-2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә эш итүнең республика стратегиясе турында” 2013 елның 11 февралендәге 90 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү” дәүләт программасын раслау турында2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы карары. |
| Муниципаль Программаның муниципаль заказчысы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| Муниципаль программаның төп максаты | 1. Халыкның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңаларын формалаштыру.<br>2. Яшьләрне физкультура-спорт эшчәнлегенә җәлеп итү исәбенә халык арасында авырулар һәм яшьләр арасында криминоген хәлнең кимүе.<br>3. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру.<br>4. Арча муниципаль районының барлык халкының сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен шартлар тудыру |
| Муниципаль программаның төп бурычлары | 1. Халыкта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә тотрыклы кызыксыну, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләре формалаштыру;<br>2. Спортчыларны әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру, шәһәрнең спорт корылмаларының матди-техник базасын ныгыту һәм үстерү;<br>3. Арча муниципаль районының һәм Татарстан Республикасы спорт |

<table>
<tr><td></td><td>командаларының югары классы спортчыларын һәм резервларын әзерләү өчен оптималь шартлар тудыру;<br>4. Халыкның төрле категорияләренә һәм төркемнәренә физик тәрбия бирү системасын модернизацияләү;<br>5. Арча районында яшәүчеләр өчен мөмкин булган физик культура һәм спорт өлкәсе инфраструктурасын булдыру һәм үстерү;<br>6. Балалар һәм яшьләр өчен спортның төрле төрләре буенча календарь укыту-спорт чараларын уздыру өчен шартлар оештыру;<br>7. Яшәү урыны буенча спорт-савыктыру чараларын оештыру һәм үткәрү өчен шартлар тәэмин итү;<br>8. Гомумшәһәр спорт-массакүләм чараларын оештыру һәм уздыру өчен шартлар тудыру;<br>9. Шәһәр халкының төрле категорияләре өчен массакүләм спорт-савыктыру чараларын оештыру һәм үткәрү өчен шартлар тудыру;<br>10. Сәламәт яшәү рәвешенең мөһим өлеше буларак физик культураны һәм спортны пропагандалауны камилләштерү;<br>11. Яшьләр инфраструктурасын үстерү һәм тотрыклы эшләве;<br>12. Физкультура-спорт эшчәнлеген оештыру-идарә итү, кадрлар, фәнни-методик тәэмин итүне үстерү</td></tr>
<tr><td>Муниципаль программаның төп чараларын башкаручылар</td><td>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге”<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесы<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесы<br>Арча муниципаль районының социаль яклау идарәсе</td></tr>
<tr><td>Муниципаль программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2021 – 2025 еллар</td></tr>
<tr><td>Муниципаль программаның максатына ирешү Индикаторлары</td><td>Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2025 ел ахырына планлаштырыла:<br>- физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче район халкының өлешен 67,3 процентка җиткерү;<br>- халыкка түләүле физкультура-спорт хезмәтләре күрсәтү күләмен һәм сыйфатын арттыру;<br>- гражданнарның авыру дәрәҗәсен кимету, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәрге һәм хәрби хезмәткә чакырылу яшендәге егетләрнең физик әзерлеген яхшырту;<br>-республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда чыгыш ясаучы Арча муниципаль районы спортчылары санын арттыру;<br>мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне физик культура һәм спорт чаралары белән физик реабилитацияләү һәм социаль адаптацияләү ролен арттыру</td></tr>
<tr><td>Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм</td><td>Җирле бюджет акчалары, бюджеттан тыш акчалар, республика бюджеты акчалары.<br><table><tr><td>Финанслау</td><td>2021.</td><td>2022ел</td><td>2023ел</td><td>2024ел</td><td>2025 ел</td></tr></table></td></tr>
</table>

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| чыганаклары | **чыганагы** | | | | | |
| | **Республика бюджеты** | 1280,5 | 1329,34 | 1914,97 | 1458,09 | 1419,1 |
| | **Җирле бюджет** | 70702,8 | 87408,7 | 81268,52 | 81995,8 | 99268,5 |
| | **Бюджеттан тыш чыганаклар** | 3 400,00 | 3546,5 | 3 000,0 | 3 200,0 | 5400,0 |
| | **Барысы** | **75383,3** | **92284,54** | **86183,49** | **86653,89** | **106 087,6** |
| | Искәрмә: программаны финанслау күләмнәре фаразланган характерда була һәм, шул елга тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны уртак финанслауга федераль һәм республика бюджетларыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. | | | | | |

## ПРОБЛЕМАНЫҢ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 17 ноябрендәге 1662-р номерлы карары белән расланган 2020 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең озак сроклы социаль-икътисадый үсеше концепциясе нигезендә спортны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлеше булып халыкның тормыш сыйфатын яхшырту өчен шартлар тудыру, шул исәптән социаль мохит сыйфатын һәм кешеләрнең яшәү шартларын яхшырта торган системалы үзгәртеп корулар аша кеше потенциалын үстерү тора.

Физик культураны һәм спортны үстерү Арча муниципаль районы социаль-икътисадый үсешенең бер өлеше булып тора. Әлеге тармакта өстенлекле юнәлешләр булып халыкның барлык яшьтәге һәм социаль төркемнәрен даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә тарту өчен шартлар тудыру, республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда район исеменнән чыгыш ясаучы югары квалификацияле спортчыларны әзерләү өчен шартлар тудыру, физик һәм әхлакый яктан сәламәт яшь буынны тәрбияләү тора. Физик культура һәм спорт район халкын сәламәтләндерүдә, балаларга һәм яшьләргә гражданлык һәм патриотик тәрбия бирүдә мөһим чара булып тора.

Соңгы елларда Арча муниципаль районында физик культура һәм спорт үсешендә уңай үзгәрешләр булды. Физик культура һәм спорт өлкәсенең матди базасын, кадрлар потенциалын үстерү, сәламәт яшәү рәвешенә мәгълүмати ярдәм күрсәтү буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән актив эшләү Арча районы халкын даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итүгә хезмәт итте.

Спорт инфраструктурасын үстерү һәм акрынлап камилләштерү өлкәсендә уңай динамика күзәтелә. 2023 ел ахырына Арча муниципаль районы территориясендә 203 спорт объекты эшли:

Асфальт түшәлгән йөгерү җиңел атлетика юлы белән 1500 урынга исәпләнгән 1 стадион,
65 яссы корылма (50 – волейбол һәм баскетбол мәйданчыклары, 15 футбол кыры)
2 бассейн
47 спорт залы
27 хоккей мәйданчыгы
1 тир
1 чаңгы базасы
1 “Арча-Арена” боз спорт сарае
29 универсаль спорт мәйданчыгы
5 урам тренажерлары
23 башка спорт корылмасы

ГТО нормаларын үтәү өчен 1 мәйданчык

Район территориясендә ике спорт мәктәбе эшли – “Арча” (1482 бала) һәм “Арча Арена” (224 бала), аларда 1706 укучы спорт белән шөгыльләнә.

Шәһәр һәм район халкының түләүле нигездә “Арча” спорт комплексындагы бассейнга, “Арча-Арена” боз сараена бару мөмкинлеге бар.

Ведомство буйсынуындагы һәр учреждениедә түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәя прейскурантлары, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә – аз тәэмин ителгән һәм күпбалалы гаиләләрдәге балаларга һәм яшүсмерләргә, ятимнәргә һәм опекада торучыларга, инвалидларга һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә, КДН һәм ПДНда исәптә торучыларга.

Районның спорт юнәлешендәге муниципаль өстәмә белем бирү учреждениеләре (балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре) һәм мәгариф учреждениеләре өчен спорт инвентарьларын сатып алу проблемалары кискен кала.

Бу системаны тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыруга программа чаралары ярдәм итә

Шулай ук мәгълүмат белән тәэмин итүгә, сәламәт яшәү рәвешен тәшкил итүче физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүне актив пропагандалауга зур игътибар бирергә кирәк.

Арча муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендәге эш йомгакларына анализ ясап, муниципаль программаны гамәлгә ашыруның уңай әһәмияткә ия булуын билгеләп үтәргә була. Ул спорт корылмаларының матди-техник базасын ныгытырга, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә район халкын җәлеп итәргә мөмкинлек бирде. Хәзерге вакытта яңа муниципаль программа эшләү һәм раслау зарурлыгы туды, анда 2020-2024 елларга Арча муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре чагылдырылырга тиеш.

Программаны куллану бюджет ассигнованиеләре белән максималь нәтиҗәле идарә иткәндә күрсәтелгән проблемаларны хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк, бу хәл ителгән проблемаларны хәл итүгә комплекслы якын килүне тәэмин итәчәк, шулай ук Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен планлаштыру һәм мониторинглауны тәэмин итәчәк. Программаны гамәлгә ашыру уңай тенденцияләрне ныгытырга, Арча муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү буенча максатчан эшне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыру һәм үстерү физик культура һәм спорт өлкәсендә сәясәтнең төп стратегик өстенлеге булып тора. Шуңа бәйле рәвештә дәүләт белән гражданинның көндәлек мөнәсәбәтләрендә үтә күренмәлелеккә, төгәллеккә һәм гадилеккә ирешергә кирәк. Бу мөнәсәбәтләрнең төп бурычы – кешеләрнең яшәү шартларын яхшырту. Бүгенге көндә яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенең төп эш юнәлеше булып яшәү урыны буенча яшьләрнең һәм өлкәннәрнең физкультура-массакүләм хәрәкәтен киңәйтү тора.

Балаларны савыктыру лагерьларының матди базасын үстерү буенча эшне дәвам итәргә, ял итү формаларын камилләштерергә кирәк.

Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенең алдагы елларга спорт-массакүләм һәм физкультура-савыктыру эшенең төп максаты – Арча муниципаль районында уңайлы климат тудыру, күпсанлы халыкны системалы рәвештә физик культура белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

Тапшырылган спорт объектларының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү мәсьәләләре безнең өчен көннән-көн актуальләшә бара. Шул ук вакытта балалар спортына аерым игътибар бирергә кирәк, балалар, яшьләр һәм гаилә ялы өчен корылмаларның һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итәргә кирәк.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә үсешнең оештыру-икътисадый механизмын камилләштерү буенча төп чаралар:

- төрле яшь төркемнәрендәге гражданнарның уку, хезмәт һәм ял режимына физик культураны һәм спортны кертү;
- спортның төрле төрләре буенча Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе җыелма командалары өчен спорт резервы, югары классны спортчылар әзерләүне тәэмин итү;
- физкультура-савыктыру һәм спорт-массакүләм чараларның календарь планнарын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

- традицияләрне, гореф-гадәтләрне һәм икътисадый хәлне исәпкә алып, халыкның төрле категорияләренең һәм төркемнәренең физкультура-спорт эшчәнлегенә ихтыяҗларын канәгатьләндерә торган шартлар тудыру;

- мәгариф учреждениеләрендә дәрестән тыш дәресләр, шул исәптән спорт ярышлары һәм бәйрәмнәр оештыру һәм үткәрү, яшәү урынында һәм ял паркларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру.

- ятим балалар, “авыр” яшүсмерләр, инвалидлар арасында физик культура һәм спортны үстерү программасын, шулай ук яшүсмерләр арасында наркоманияне, алкоголизмны һәм башка тайпылышларны җиңүгә юнәлдерелгән махсус программаларны кабул итү һәм гамәлгә ашыру. Халыкның барлык яшь төркемнәре өчен (хезмәт коллективларында, яшәү һәм ял итү урыннарында, мәгариф учреждениеләрендә) массакүләм спорт төрләре буенча ярышлар санының шактый артуы.

Программаның төп максатлары булып тора:

1.Массакүләм физик культура һәм спортны үстерү, халыкның сәламәтлеген ныгыту, Арча муниципаль районының спорт имиджын күтәрү.

2. Халыкның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңаларын формалаштыру.

3. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру.

4. Арча муниципаль районының барлык халкының сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен шартлар тудыру

Күрсәтелгән максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Халыкта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә тотрыклы кызыксыну, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләре формалаштыру;

2. Спортчыларны әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру, районның спорт корылмаларының матди-техник базасын ныгыту һәм үстерү;

3. Арча муниципаль районының һәм Татарстан Республикасы спорт командаларының югары класслы спортчыларын һәм резервларын әзерләү өчен оптималь шартлар тудыру;

4. Халыкның төрле категорияләренә һәм төркемнәренә физик тәрбия бирү системасын модернизацияләү;

5. Арча районында яшәүчеләр өчен мөмкин булган физик культура һәм спорт өлкәсе инфраструктурасын булдыру һәм үстерү;

6. Балалар һәм яшьләр өчен спортның төрле төрләре буенча календарь укыту-спорт чараларын уздыру өчен шартлар оештыру;

7. Яшәү урыны буенча спорт-савыктыру чараларын оештыру һәм үткәрү өчен шартлар тәэмин итү;

8. Гомумшәһәр спорт-массакүләм чараларын оештыру һәм уздыру өчен шартлар тудыру;

9. Район халкының төрле категорияләре өчен массакүләм спорт-савыктыру чараларын оештыру һәм үткәрү өчен шартлар тудыру;

10. Сәламәт яшәү рәвешенең мөһим өлеше буларак физик культураны һәм спортны пропагандалауны камилләштерү;

11. Яшьләр инфраструктурасын үстерү һәм тотрыклы эшләве;

12. Физкультура-спорт эшчәнлеген оештыру-идарә, кадрлар, фәнни-методик тәэмин итүне үстерү.

## 1. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОКЛАРЫ ҺӘМ ЭТАПЛАРЫ

Программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2021-2025 еллар.

## 2. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ РЕСУРСЛАР

Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен җирле бюджет акчаларын, бюджеттан тыш акчаларны, республика бюджеты акчаларын куллану күздә тотыла.

| Финанслау чыганагы | 2021ел | 2022ел | 2023ел | 2024ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Республика бюджеты | 1280,5 | 1329,34 | 1914,97 | 1458,09 | 1419,1 |
| Җирле бюджет | 70702,8 | 87408,7 | 81268,52 | 81995,8 | 99 268,5 |
| Бюджеттан тыш чыганаклар | 3400,00 | 3546,5 | 3 000,0 | 3 200,0 | 5400,0 |
| **Барысы** | **75383,3** | **92284,54** | **86183,49** | **86653,89** | **106 087,6** |

Искәрмә: программаны финанслау күләмнәре фаразланган характерда була һәм, шул елга тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны уртак финанслауга федераль һәм республика бюджетларыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## 3. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ҺӘМ АНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Башкарма хакимиятнең программада катнашучыларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм координацияләү өчен җаваплы органы булып Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге тора, ул тармак учреждениеләре, предприятие җитәкчеләре һәм башка оешмалар белән берлектә:

- программа чаралары исемлеген, аларны гамәлгә ашыру чыгымнарын, шулай ук программаны гамәлгә ашыру механизмын төгәлләштерү буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр әзерли;
- максатчан индикаторлар исемлеген һәм аларның кварталлар буенча бүленешен төгәлләштерә;
- квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр, программаны гамәлгә ашыруның барышы турында хисап әзерли һәм аны Арча муниципаль районы башкарма комитетына тапшыра.

Хисап мәгълүматын җыю һәм туплау өчен Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җаваплы.

Программаны башкаручылар хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә Программа чараларының үтәлеше турында мәгълүмат тапшыралар.

## 4. МАКСАТЛАР ИНДИКАТОРЛАРЫ, МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ ИКЪТИСАДЫЙ, СОЦИАЛЬ ҺӘМ ЭКОЛОГИК НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ.

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү программа максатларына ирешү дәрәҗәсен бәяләү һәм бурычларны хәл итү нигезендә хисап елында фактта ирешелгән күрсәткечләр (индикаторлар) күрсәткечләрен чагыштыру юлы белән башкарыла.

Программаның мөһим социаль-икътисадый нәтиҗәсе физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр санын арттыру булачак, нәтиҗәдә бу район халкының сәламәтлеген ныгытуга ярдәм итәчәк.

Балалар-яшүсмерләр спорты үсеше нәтиҗәсендә югары квалификацияле спортчыларның төрле дәрәҗәдәге ярышларда уңышлы чыгыш ясау өчен әзерлек дәрәҗәсе артачак, республика Спартакиадасы исәбенә иң күп төрле ярышларда катнашучы спортчылар саны артачак.

Арча муниципаль районы халкының төрле категорияләрен актив рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү процессына җәлеп итү наркомания, алкоголизм, тәмәке тарту һәм

башка зарарлы гадәтләрне киметергә, авыруларны киметергә, эшкә сәләтлелекне арттырырга һәм район халкының гомер озынлыгын арттырырга ярдәм итәчәк.

Муниципаль программаның бюджет нәтиҗәлелеге физик культура һәм спорт өлкәсендәге сәясәтне гамәлгә ашыру кысаларындагы чараларга юнәлдерелгән чыгымнарның нәтиҗәлелеген арттырудан гыйбарәт.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның экологик нәтиҗәлелеге чагыла:

- үсеп килүче буынны һәм яшьләрне әхлакый тәрбияләүдә, шул исәптән әйләнә-тирә мохиткә сакчыл мөнәсәбәттә;

- хуҗалык әйләнешендә файдаланылмаган җир кишәрлекләрен спорт мәйданчыклары итеп төзекләндерү өчен файдалануда.

## 5. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕҺӘМ ТАСВИРЛАМАСЫ

| № п/п | Чаралар | Башкаручылар | Башкару вакыты | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме (мең сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1. Физкультура-массакүләм эшне, халыкның хәрәкәт активлыгын үстерү | | | | | | | | | |
| 1.1 | Үткәрелә торган физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының комплексны планнарын эшләү<br>- яшәү урыны буенча<br>- уку һәм хезмәт эшчәнлеге урыны буенча<br>- авыл халкы белән<br>- инвалидлар белән эшләгәндә<br>- төрле юнәлештәге иҗтимагый оешмалар һәм клублар белән<br>- спорт ветераннары белән | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2021 – 2025 | Җирле бюджет | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1.2 | Яшәү урыны буенча барлык яшьтәге халыкның киң катнашында физкультура-савыктыру һәм спорт-массакүләм чаралар үткәрү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2021 – 2025 | Җирле бюджет | 98,00 | 198,0 | 973,04 | 68,0 | 68,0 |
| 1.3 | Предприятиеләр | Яшьләр | Ел саен | Җир | 150,00 | 250,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәткәрләре Спартакиадасын оештыру һәм уздыру | эшләре һәм спорт бүлеге | | ле бюд жет | | | | | |
| 1.4 | Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында спорт эшен оештыру, адаптив физик культураны һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, өлкәннәрне сәламәтләндерү физкультурасына тарту | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Социаль яклау бүлеге | 2021 – 2025 | Жир ле бюд жет | 73,00 | 73,00 | 73,00 | 73,00 | 73,00 |
| 1.5 | Бөек татар шагыйре Тукайның туган көненә багышланган “ТУКАЙ SKI-марафоны” һәм “Тукай-марафоны” чаңгы марафонын оештыру һәм үткәрү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2021 – 2025 | Жир ле бюд жет | 280,00 | 280,00 | 123,6 | 80,0 | 80,0 |
| 1.6 | Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү мөмкинлеген тәэмин итү буенча халык өчен шартлар тудыру | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесы Балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе Эчке эшләр министрлыгының ТР Арча районы буенча бүлеге | 2021 – 2025 | Жир ле бюд жет | 45.90 | 45.90 | 45.90 | 45,90 | 45,90 |
| 1.7 | Гомуми белем | “Мәгариф | 2021 – | Жир | 60,00 | 60,00 | 50,0 | 50,0 | 50,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бирү учреждениеләре арасында физкультура-савыктыру һәм спорт эшен иң яхшы оештыруга смотр-бәйгеләр үткәрү | идарәсе” муниципаль учреждениесы Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2025 | ле бюджет | | | | |
| 2. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, социаль тискәре күренешләрне кисәтү | | | | | | | | |
| 2.1 | Стационар һәм мәктәп яны лагерьларында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чаралары үткәрү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесы | 2021 - 2025 | Җирле бюджет | 65,00 | 65,00 | 45,0 | 45,0 | 45,0 |
| 2.2 | КДН, ПДНда исәптә торучы балигъ булмаганнарны мәктәп коллективларының иҗади эшчәнлегенә җәлеп итү, төрле мәдәни-массакүләм, спорт чараларында һәм секцияләрендә катнашу | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесы Балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе Мәдәният идарәсе | 2021 - 2025 | Җирле бюджет | 37,00 | 37,00 | 37,00 | 37,00 | 37,00 |
| 2.3 | Тәмәке тартуны, алкоголизмны, наркоманияне кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм үткәрү | “Арча үзәк район хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесы Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге “Мәгариф | 2021 – 2025 | Җирле бюджет | 80,00 | 80,00 | 80,00 | 80,00 | 80,00 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | идарәсе” муниципаль учреждениесы | | | | | | | |
| 3. Югары казанышлар спортын үстерү | | | | | | | | | |
| Ярышларны һәм конкурсларны оештыруның һәм уздыруның нәтиҗәле системасын булдыру | | | | | | | | | |
| 3.1 | Ел саен үткәрелә торган смотр - бәйгеләр оештыру һәм уздыру:<br>- Спортның олимпия төрләре буенча иң яхшы тренер һәм спортчы<br>- Олимпия уеннарына карамаган спорт төрләре буенча иң яхшы тренер һәм спортчы<br>- спортның уен төрләре буенча иң яхшы команда | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2021 – 2025 | Җирле бюджет | 105,00 | 105,00 | 79,0 | 79,0 | 79,0 |
| 3.2 | Районның әйдәп баручы спортчыларының, җыелма һәм клуб командаларының чемпионатларда һәм беренчелекләрдә, РТ турнирларында, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда катнашуы | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2021 – 2025 | Җирле бюджет | 525,00 | 697,3 | 1221,2 | 225,0 | 225,0 |
| 3.3 | «Арча-Арена» спорт мәктәбе спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында һәм (яисә) хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында катнашуы | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2021-2025 | Республика бюджеты | 359,9 | 890,3 | 1031,3 | 1004,7 | 1419,1 |
| 3.4 | Татарстан Республикасының | Яшьләр эшләре | 2021 - 2025 | Республи | 387,75 | 425,10 | 439,04 | 501,37 | 421,39 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | спорт резервын әзерләүче физкультура-спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу | һәм спорт бүлеге | | ка бюджеты | | | | | |
| 4. Яшьләрнең гражданлык үсеше, рухи-әхлакый тәрбиясе өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | |
| 4.1 | Яшьләргә хәрби-патриотик, рухи-әхлакый, экологик тәрбия бирү өлкәсендә район бәйгеләре, проектлары һәм программалары оештыру | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге "Мәгариф идарәсе" муниципаль учреждениесы Район хәрби комиссариаты Мәдәният идарәсе | 2021 – 2025 | Җирле бюджет | 75,00 | 75,00 | 55,0 | 55,0 | 55,0 |
| 4.2 | Ватан тарихының истәлекле даталарына бәйле чараларны оештыру һәм үткәрү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге "Мәгариф идарәсе" муниципаль учреждениесы Мәдәният идарәсе | 2021 – 2025 | Җирле бюджет | 70,00 | 70,00 | 70,00 | 70,00 | 70,00 |
| 4.3 | Ел саен үткәрелә торган бәйрәмнәрдә (Яшьләр көне, физкультурачылар көне, Шәһәр көне) спорт чараларын оештыру һәм уздыру | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2021 – 2025 | Җирле бюджет | 207,60 | 307,6 | 495,96 | 157,6 | 157,6 |
| | ИТОГО | | | | 2638,75 | 3128,8 | 4778,04 | 2698,17 | 1165,5 |
| 5. Спорт челтәрен карап тору | | | | | | | | | |
| 5.1 | "Арча" спорт мәктәбе" | | 2021 – 2025 | Җирле | 68359,0 | 83960,0 | 80099,2 | 80830,3 | 98103,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | муниципаль бюджет учреждениесын, “Арча Арена” спорт мәктәбе” муниципаль бюджет учреждениесын Карап тоту | | | бюджет | | | | | |
| | | | | Республика бюджеты | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| | | | | Бюджеттан тыш чыганаклар | 3400,0 | 3545,5 | 3000,0 | 3200,0 | 5400,0 |
| 5.2 | Физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль биремне үтәү максатларында спорт объектларының террорчылыктан саклануын тәэмин итү өчен җайланмалар сатып алу | | 2<br>2021 - 2025 | Республика бюджеты | 0,0 | 495,5 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| | **ИТОГО** | | | | **72254,5** | 87506,5 | 83485,32 | 84030,3 | 104922,1 |
| | **ВСЕГО** | | | | **75383,3** | 92284,54 | 86183,49 | 86653,89 | 106087,6 |

Искәрмә: программаны финанслау күләмнәре фаразланган характерда була һәм, шул елга тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны уртак финанслауга федераль һәм республика бюджетларыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.